МИНИСТЕРСТВО
ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

21.03.2018 г. Казань № под-504/16___

**Татарстан республикасы
Гомуми белем бирү оешмалары
Укытучыларының һөнәри үсешенә
грант ярдәме турында**

Республика гомуми белем бирү оешмалары укытучыларында педагогик эшчәнлектә һөнәри компетенцияләр дәрәҗәсен арттыруга һәм аларның иҗади мөмкинлекләрен үстерүгә, шулай ук иң яхшы педагогик тәҗрибәне таратуга, укытучы хезмәтенең абруен үстерүгә алга таба этәргеч бирү максатыннан чыгып, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының һөнәри үсешенә грант ярдәме турында нигезләмәне (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Грант ярдәмен финанслауның Министрлыкның җыелма сметасында күздә тотылган акчалар хисабына башкарылуын билгеләргә.

7. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
министр Э.Н.ФӘТТАХОВ

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2016 елның 21 мартындагы под-504/16 номерлы боерыгы белән расланды

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫ УКЫТУЧЫЛАРЫНЫҢ ҺӨНӘРИ ҮСЕШЕНӘ ГРАНТ ЯРДӘМЕ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының һөнәри үсешенә грант ярдәме (алга таба – Грант ярдәме), республика гомуми белем бирү оешмалары укытучыларында педагогик эшчәнлектә һөнәри компетенцияләр дәрәҗәсен арттыруга һәм аларның иҗади мөмкинлекләрен үстерүгә алга таба этәргеч бирү максатыннан чыгып, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан гамәлгә куелды.

Грант ярдәме Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында түбәндәге фәннәр: рус теле, татар теле, әдәбият, инглиз теле, алман теле, француз теле, математика, информатика, химия, физика, биология, география, тарих, җәмгыять белеме, физик культура, технология, ОБЖ фәннәре буенча гомуми белем бирүнең төп мәгариф программаларын тормышка ашыручы Татарстан Республикасы мәгариф системасының педагогик хезмәткәрләренә керүче, бу Нигезләмәдә билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә туры килүче беренче категория укытучылар; шулай ук башлангыч сыйныф укытучылары (алга таба – Грант алучы) өчен билгеләнгән.

1.2. Грант ярдәме алуга дәгъва кылучы 2014 елга кадәр алынган беренче квалификация категориясенә ия булырга; соңгы өч ел эчендә укучылары арасында республика, Бөтенроссия һәм халыкара олимпиадаларның муниципаль этабында җиңүчеләр һәм/яки призерларга ия булырга яки соңгы өч ел эчендә һөнәри осталык конкурсларының («Ел укытучысы») муниципаль яисә республика этапларында җиңүче һәм/яки призеры булып торырга тиеш. Башлангыч сыйныф укытучылары соңгы дүрт ел эчендә үз укучылары арасында республика олимпиадаларының муниципаль этабында җиңүчеләр һәм/яки призерларга ия булырга яисә соңгы өч ел эчендә һөнәри осталык конкурсларының («Ел укытучысы») республика этапларында җиңүче һәм/яки призеры булып торырга тиеш.

Грант ярдәме алуга конкурста соңгы өч ел эчендә укучылары бердәм дәүләт имтихан йомгаклары буенча канәгатьләндерми торган нәтиҗәләр күрсәткән, төп дәүләт имтиханы йомгаклары буенча төп гомуми белем бирү турында аттестат алмаган (билгеле бер фән буенча өлгермәү сәбәпле) укытучылар кертелми.

Грант ярдәменә дәгъва кылучы төп эш урыны буенча гомуми белем бирү оешмасының штаттагы хезмәткәре булырга тиеш.

1.3. Грант ярдәме булып, физик затлар керемнәренә салымнан һәм Пенсия фондына, Социаль иминиятләштерү фондына, РФ Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе федераль

фондына иминиятләштерү кертемнәреннән тыш, укытучыларга 5 000 (биш мең) сум күләмендә конкурс нигезендә бирелә торган айлык түләү тора. Грант ярдәменә бүлеп бирелгән акчалар грант алучыларга сигез ай дәвамында түләү өчен билгеләнгән. Грант ярдәме күп дигәндә 600 укытучыга бирелә.

1.4. Грант ярдәменә дәгъва кылучыларны конкурс ярдәмендә сайлау 2016 елның 4 апреленнән 27 апреленгә кадәр әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә үткәрелә. Сайлап алу Министрлык тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 2 бүлеге нигезендә оештырыла торган Татарстан Республикасы Гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының һөнәри үсешенә грант ярдәмен тормышка ашыру буенча Республика эксперт комиссиясе тарафыннан үткәрелә.

1.5. Грант ярдәмен алуга конкурста катнашуы чорында һәм аны тормышка ашыру чорында укытучы турында күрәләтә торып дөрес булмаган яки ялган мәгълүматларның бирелүе ачыкланганда, Грант ярдәме бирү турында карар кабул ителми.

1.6. Грант алучының мәгариф оешмасы белән хезмәт мөнәсәбәтләрен өзүе очрагында Грант ярдәме бирү турында карар гамәлдән чыгарыла һәм түләүләр туктатыла. Татарстан Республикасы муниципаль районнарының мәгариф бүлекләре (идарәләре) Грант алучы белән хезмәт мөнәсәбәтләренең өзелүе турында ул эшеннән киткәннән соң 1 (бер) атна эчендә хәбәр итәргә тиеш.

## 2. Татарстан Республикасы Гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының һөнәри үсешенә грант ярдәмен тормышка ашыру буенча республика эксперт комиссиясе

2.1. Татарстан Республикасы Гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының һөнәри үсешенә грант ярдәмен тормышка ашыру буенча республика эксперт комиссиясе (алга таба – Республика эксперт комиссиясе) Министрлык тарафыннан, Грант ярдәме бирү өчен укытучыларны сайлап алу максатыннан чыгып, 9 (тугыз) кешедән – комиссия рәисеннән, комиссия рәисе урынбасары, сәркатибе һәм әгъзаларыннан төзелә.

2.2. Республика эксперт комиссиясе түбәндәгеләргә хокуклы:

Республика олимпиадалар үзәгеннән, Татарстан Республикасы Мәгариф сыйфатына мониторинг буенча республика үзәгеннән, муниципаль мәгариф идарәсе органнарыннан һәм башка оешмалардан комиссия компетенциясенә керүче мәсьәләләр буенча материаллар һәм мәгълүматлар соратып алырга;

кирәк булганда, Республика олимпиадалар үзәгеннән, Татарстан Республикасы Мәгариф сыйфатына мониторинг буенча республика үзәгеннән, муниципаль мәгариф идарәсе органнарыннан берәр вәкил – белгеч җәлеп итәргә.

2.3. Республика эксперт комиссиясе утырышларына - Республика эксперт комиссиясе рәисе, ә ул югында Республика эксперт комиссиясе рәисе урынбасары җитәкчелек итә. Республика эксперт комиссиясе утырышлары, әгъзаларының яртысыннан артыграк катнашкан очракта, хокуклы, дип санала.

2.4. Республика эксперт комиссиясенең персональ составы Министрлык боерыгы белән расланыла.

2.5. Республика эксперт комиссиясе карарлары, ачык тавыш бирү юлы белән, утырышта катнашучы Комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар бертигез булганда, рәис тавышы хәлиткеч булып тора.

2.6. Республика эксперт комиссиясе карары беркетмә нигезендә рәсмиләштерелә, аңа - рәисе, ә ул югында комиссия рәисе урынбасары кул куя.

## 3. Грант ярдәме алу өчен конкурска документлар, заявкалар тапшыру һәм конкурсны үткәрү тәртибе

3.1. Грант ярдәме алуга конкурс Министрлык боерыгы нигезендә үткәрелә.

3.2. Министрлык 2016 елның 4 апреленнән дә соңга калмыйча Министрлыкның рәсми сайтында (http://mon.tatarstan.ru) «Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының һөнәри үсешенә грант ярдәме турында» боерыкны урнаштыру юлы белән Грант ярдәме алуга конкурс үткәрү турында игълан итә.

3.3. Грант ярдәме алуга конкурста катнашу өчен, дәгъва кылучылар Министрлыкка әлеге Нигезләмәнең 3.4 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыра, һәм сайтта (http://uchiteltatarstan.ru) мәҗбүри поляларны тутыра:

фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы, җенесе, эш урыны, муниципаль район атамасы, фән, гомуми педагогик стажы, гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме, квалификация категориясе, бүләкләре, исемнәре.

3.4. Грант ярдәменә дәгъва кылучылар конкурска түбәндәге документларны тапшыра:

түбәндәгеләрне раслаган документларны:

2014 елга кадәр алынган беренче квалификация категориясенә ия булуын;

соңгы өч ел эчендә укучылары арасында республика, Бөтенроссия һәм халыкара олимпиадаларның муниципаль этабында җиңүчеләр һәм/яки призерларга ия булуын яки соңгы өч ел эчендә һөнәри осталык конкурсларының («Ел укытучысы») муниципаль яисә республика этапларында җиңүче һәм/яки призеры булып торуын;

башлангыч сыйныф укытучылары өчен: соңгы дүрт ел эчендә үз укучылары арасында республика олимпиадаларының муниципаль этабында җиңүчеләр һәм/яки призерларга ия булуын яисә соңгы өч ел эчендә һөнәри осталык конкурсларының («Ел укытучысы») республика этапларында җиңүче һәм/яки призеры булып торуын;

мотивация хаты:

Татарстан Республикасы укытучысының һөнәри үсеш моделенең биш компетенциясенә таянып, Татарстан Республикасы мәктәпләрендә укучыларның үсеш проблемаларын һәм перспективаларын (үзе укыта торган фән өлкәсендә) күзаллауны һәм дәгъва кылучының бу эшкә кертә алырлык өлешен чагылдыру зарур (500 дән 700 сүзгә кадәр);

2016 елда муниципаль районда тормышка ашырып булырдай, укучыларны үстерүгә (үзе укыта торган фән өлкәсендә) юнәлдерелгән проект тасвирламасы;

Татарстан Республикасы муниципаль район мәгариф бүлеге (идарә) башлыгы белән килештерелгән, дәгъва кылучы эшли торган гомуми белем бирү оешмасы директорының бәяләмәсе.

3.5. Документлар рәсми сайтка (http://uchiteltatarstan.ru) электрон рәвештә 2016 елның

11 апреленнән дә соңга калмыйча җибәрелә. Документларның әлеге сроктан соңрак тапшырган очракта, дәгъва кылучы конкурска кертелми.

3.6. Республика эксперт комиссиясе 2016 елның 18 апреленә кадәр тапшырылган документларга башлангыч экспертиза үткәрә. Шул ук вакытта һәр документлар пакетына карата документларның әлеге Нигезләмә таләпләренә туры килүе турында Республика эксперт комиссиясенең ике әгъзасы тарафыннан язмача эксперт нәтиҗәләре ясала.

3.7. Тапшырылган материалларны анализлау йомгаклары буенча, комиссия рәисе раслаган график нигезендә 2016 елның 19 апреленнән 25 апрельгә кадәр үткәреләчәк турыдан-туры сайлап алу этабында Республика эксперт комиссиясе тарафыннан алга таба карап тикшерү өчен, документлары әлеге Нигезләмә таләпләренә туры килә торган дәгъва кылучылар сайлап алына. График 2016 елның 18 апреленнән дә соңга калмыйча, электрон документлар әйләнеше системасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының мәгариф идарәсе органнарына җибәрелә.

3.8. Республика эксперт комиссиясе шәхси әңгәмә рәвешендә Грант ярдәме алуга дәгъва кылучыларны сайлап алуның турыдан-туры этабын үткәрә.

Грант ярдәмен алучыларны сайлап алу өчен, http://uchiteltatarstan.ru рәсми сайтында Республика эксперт комиссиясенең һәр әгъзасына системага керү өчен логин һәм пароль бирелә. Күзгә-күз әңгәмә үткәрү вакытында комиссия укытучының профайлын һәм документларны тикшерү нәтиҗәләрен, шул исәптән тапшырылган материалларны анализлаганда ике эксперт тарафыннан ясалган искәрмәләрне карый. Дәгъва кылучы әңгәмә барышында биш компетенция буенча бәяләнә: уңышлы эшләүче лидер; инновацион практик; актив гражданин; компетентлы педагог; җаваплы остаз. Республика эксперт комиссиясе әгъзалары барлык биш компетенция буенча 0дән 5кә кадәр баллар куя. Нәтиҗәдә һәр укытучы буенча, барлык экспертлар бәяләреннән чыгып, уртача балл чыгарыла. Җыелган баллар рейтингыннан чыгып, җиңүчеләр билгеләнелә, барлык фәннәрне исәпкә алып, күп дигәндә 600 укытучы.

3.9. Конкурс йомгаклары буенча, Республика эксперт комиссиясе 2016 елның 25 апреленә кадәр грант алучылар исемлекләрен булдыра һәм раслый.

3.10. Министрлык грант алучыларның расланылган исемлеген 2016 елның 27 апреленә кадәр үзенең рәсми сайтына урнаштыра.

## 4. Йомгаклау нигезләмәләре

4.1. Грант ярдәмен финанслау Министрлыкның җыелма сметасында күздә тотылган акчалар хисабына башкарыла.

4.2. Грант ярдәме, «2016 елда Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының һөнәри үсешенә грант ярдәмен үткәрү йомгаклары турында» Министрлык боерыгы нигезендә, башка бюджетара трансфертлар рәвешендә муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә.

Субсидия күчерүгә нигез булып Министрлык белән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге арасында төзелгән грант ярдәме күрсәтү өчен муниципаль берәмлек бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү тора.

4.3. Грант алучының мәгариф оешмасы белән хезмәт мөнәсәбәтләрен өзүе очрагында Грант ярдәме бирү турында карар гамәлдән чыгарыла һәм түләүләр туктатыла. Шул ук

вакытта Грант алучы эшеннән киткәннән соң түләнгән акчаларны Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарырга тиеш.

4.5. 2016 елның декабрендә Грант алучылар Министрлыкка мотивация хатында күрсәтелгән проект чараларын тормышка ашыру турында хисап тапшырырга бурычлы. 2016 елда Грант ярдәмен тормышка ашыруның нәтиҗәсе турында йомгаклау хисабын Министрлык үзенең рәсми сайтында (http://mon.tatarstan.ru) 2017 елның 20 гыйнварыннан да соңга калмыйча урнаштыра.

4.6. Грант ярдәме бирүдән баш тартуга укытучы закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерергә мөмкин.

---